**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«13» 01 2023 ел Яр Чаллы ш. №24

Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең генераль планын эшли башлау турында

Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге территориясен тотрыклы үстерү мәсьәләләрен җайга салу максатында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Тукай муниципаль районы Советының 2016 елның 2 ноябрендәге 17/5 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү мөмкин булмаганга күрә, аның «Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 31 декабрендәге 507-ФЗ номерлы Федераль законга, «Федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны территориаль планлаштыру документларында тасвирлау һәм сурәтләү таләпләрен раслау һәм Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2016 елның 7 декабрендәге 793 номерлы боерыгының үз көчен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2018 елның 9 гыйнварендагы 10 номерлы боерыгына туры килмәве сәбәпле,

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү буенча документлар әзерли башлау турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 июлендәге 2025 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлегенең генераль планын эшли башларга.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин